**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 18 февраль № 100

г. Казань

2015 елда авыл җирендә урнашкан Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру чаралары комплексын раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2013 – 2020 елларга «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Балаларга мәктәпкәчә, гомуми һәм өстәмә белем бирүне үстерү» ярдәмче программасы кысаларында авыл җирендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыруга федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр бирү һәм бүлү турында» 2014 ел, 29 декабрь, 1597 нче карарын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2015 елда авыл җирендә урнашкан Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру чаралары комплексын (алга таба – Чаралар комплексы) расларга.

2. Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгын Чаралар комплексын тормышка ашыру буенча вәкаләтле орган итеп билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\100.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 18 февраль, 100 нче
карары белән расланды

**2015 елда авыл җирендә урнашкан Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру чаралары комплексы**

**1. Гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен Татарстан Республикасында тудырылган шартлар турында мәгълүмат**

Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы, мәгариф белән идарә итүче муниципаль органнар эшчәнлеге үсеп килүче буынның сәламәтлеген ныгытуга, балаларны һәм яшүсмерләрне әледән-әле һәм массакүләм физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә тарту өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән. Бүген бу эшнең аерым нәтиҗәләре бар.

Республикада 2010 – 2015 елларга Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү буенча «Киләчәк» – «Будущее» стратегиясе эшләнде, анда гомуми белем бирүнең иң мөһим максатларыннан берсе булып балаларның физик һәм әхлакый сәламәтлеге билгеләнгән.

Физкультура-савыктыру эшен оештыру өчен тиешле инфраструктура булу аерым әһәмияткә ия.

1473 гомуми белем бирү оешмасында (аларның гомуми санынннан 97,3 процент) 1534 спорт залы эшли.

Гомуми белем бирү оешмаларының спорт-савыктыру инфраструктурасы түбәндәге объектлардан тора:

спорт мәйданчыклары – 1563;
хоккей тартмалары – 555 (36,6 процент);
футбол кырлары – 1001 (66 процент);
бассейннар – 33 (2,1 процент);
тренажер заллары – 118 (7,8 процент);
теннис заллары – 78 (5,2 процент);
бию заллары – 225 (14,9 процент);
башка объектлар – 100 (6,6 процент).

Республика гомуми белем бирү оешмаларының спорт җиһазлары белән тәэмин ителеше түбәндәгеләрне тәшкил итә:

55,8 процент (2012/2013 уку елы – 53,92 процент) – гимнастика җиһазлары;
59 процент (2012/2013 уку елы – 55,87 процент) – чаңгы базасы;
60,6 процент (2012/2013 уку елы – 57,92 процент) – спорт уеннары өчен җиһазлар;

58,3 процент (2012/2013 уку елы – 56,32 процент) – җиңел атлетика белән шөгыльләнү өчен җиһазлар.

2012, 2013 елларда гомуми белем бирүнең төбәк системаларын модернизацияләү чаралары комплексы кысаларында гомуми белем бирү оешмаларына спорт инвентаре һәм җиһазлары кайтарту гамәлгә ашырылды. Спорт инвентаре һәм җиһазлары 806 гомуми белем бирү оешмасына куелды.

Республиканың гомуми белем бирү оешмалары базасында физкультура-савыктыру һәм спорт юнәлешендәге түгәрәкләр һәм секцияләр эшли. Спортның уен төрләре буенча түгәрәкләр һәм секцияләр аеруча популяр:

волейбол – 791 (14 296 укучы);

баскетбол – 689 (18 626 укучы);

хоккей – 319 (5 588 укучы);

футбол – 379 (8 139 укучы);

мини-футбол – 467 (5 878 укучы).

Шулай ук көрәшнең төрле төрләре, җиңел атлетика, өстәл теннисы, чаңгы ярышлары, шахмат, туризм түгәрәкләренә һәм спекцияләренә ихтыяҗ бар.

Өстенлекле бурычларның берсе – муниципаль берәмлекләрнең физкультура-савыктыру объектларыннан максималь файдаланып, спорт белән шөгыльләнүне массакүләмгә әйләндерү.

Республиканың гомуми белем бирү оешмалары физик культура буенча дәресләр үткәрү һәм дәрестән тыш спорт-савыктыру эшчәнлеген оештыру өчен муниципаль дәрәҗәдәге спорт-савыктыру объектлары: спорт сарайларыннан, спорт комплексларыннан, боз сарайларыннан, йөзү бассейннарыннан, стадионнардан актив файдалана.

Гомуми белем бирү оешмаларының муниципаль спорт-савыктыру оешмаларыннан файдалануы турындагы мәгълүматлар түбәндәге таблицада китерелә.

| Күрсәткеч | 2010/2011 уку елы | 2011/2012 уку елы | 2012/2013 уку елы | 2013/2014 уку елы |
|---|---|---|---|---|
| Физик культура дәресләре үткәрүче мәктәпләр саны/ укучылар саны | 655 (31%) / 129 148 (33,5%) | 707 (37,5%) / 137 938 (37%) | 624 (39,3%) / 161 309 (43%) | 621 (41, 3%)/ 175 176 (47%) |
| Дәрестән тыш спорт-савыктыру эшен оештыручы мәктәпләр саны/ укучылар саны | 1848 (86%)/ 218 301 (56,6%) | 1781 (94,4%)/ 257 720 (69%) | 1514 (96%)/ 285 103 (77%) | 1454 (96%)/ 305 672 (82%) |

Россия Федерациясе Президентының 2010 ел, 30 июль, 948 нче Указы нигезендә республикада 2013/2014 уку елында Президент ярышлары һәм Президент спорт уеннары үткәрелде.

Әлеге чараларның максатлары һәм бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

укучыларның хәрәкәтләнү активлыгын дәрәҗәсен билгеләү;

массакүләм мәктәп спортын үстерү;

сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау;

укучыларны физик культура һәм спорт белән регуляр рәвештә шөгыльләнүгә җәлеп итү.

Президент ярышларында 201 699 укучы катнашты, бу Татарстан Республикасы укучыларының барлык саныннан 94,6 процент тәшкил итә.

Президент спорт уеннарында 148 293 укучы катнашты, бу 5 – 11 сыйныф укучылары гомуми санының 93,3 проценты дигән сүз.

Республиканың гомуми белем бирү оешмалары спортның уен төрләрен, аерым алганда, мәктәп баскетболын үстерүгә юнәлдерелгән проектларда актив катнаша.

2013/2014 уку елы сезонының «КЭС-БАСКЕТ» мәктәп баскетбол лигасы чемпионатында республиканың 740 гомуми белем бирү оешмасыннан барлыгы 13 000 нән артык укучыдан торган 1200 мәктәп командасы катнашты.

Татарстан Республикасында проектның үсеш динамикасы

| Күрсәткеч | 2009/2010 уку елы | 2010/2011 уку елы | 2011/2012 уку елы | 2012/2013 уку елы | 2013/2014 уку елы |
|---|---|---|---|---|---|
| Катнашучы мәктәпләр саны / катнашучы командалар саны | 130 / 200 | 384 / 495 | 560 /960 | 641 / 1060 | 740/ 1200 |
| Катнашучылар саны | 1500 | 2304 | 11500 | 12 742 | Более 13 000 |
| Кайтартылган туплар саны | 780 | 2 304 | 3 024 | 3 846 | 4 440 |

2013/2014 уку елында яңа спорт-савыктыру проектлары старт алды:

Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмалары командалары арасында (6 – 8 сыйныф укучылары) спортның кышкы һәм җәйге төрләре буенча I мәктәп Спартакиадасы;

гомуми белем бирү оешмалары арасында иң яхшы физик әзерлеккә республика конкурсы.

I мәктәп Спартакиадасы ярышлары программасына чаңгы ярышлары, чаңгы эстафетасы, шорт-трек, «Көмеш тимераяк» эстафетасы, спорт ориентирлашуы, алкалы хоккей, «Көрәш» татар-башкорт милли спорт көрәше, волейбол, җиңел атлетика, йөзү, бадминтон кертелде.

Ел саен Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы муниципаль берәмлекләрнең спорт-савыктыру конкурсларында һәм проектларында катнашуы буенча нәтиҗәлелек рейтингын төзи.

2013/2014 уку елы йомгаклары буенча рейтингта Яр Чаллы шәһәре, Лениногорск, Бөгелмә, Спас, Саба, Мамадыш муниципаль районнары алдынгы урынны алды.

Республикада ел саен сәламәтлеккә булышлык күрсәтүче мәктәпләр челтәре киңәя. Хәзерге вакытта сәламәтлеккә булышлык күрсәтүче 1155 мәктәп (76,3 процент), шулардан бронза дәрәҗәсендәге – 467 мәктәп (40,4 процент), көмеш дәрәҗәдәге – 596 мәктәп (51,6 процент), алтын дәрәҗәдәге 92 мәктәп (7,4 процент) эшли.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 7 февраль, 73 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында физик культура, спорт, туризмны үстерү һәм яшьләр сәясәтен тормышка ашыру нәтиҗәлелеген күтәрү» дәүләт программасы чараларын гамәлгә ашыру 2015 елда күрсәткечләрнең түбәндәге мәгънәләренә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:

| Соңгы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | 2015 ел |
|---|---|
| Халыкның гомуми санында физик культура һәм спорт белән системалы рәвештә шөгыльләнүче халык өлеше, процент | 35 |
| Россия Федерациясенең җыелма спорт командаларына кандидатлар исемлегенә кертелгән спортчылар саны, кеше | 555 |
| Укучыларның һәм студентларның гомуми санында физик культура һәм спорт белән системалы рәвештә шөгыльләнүче укучылар һәм студентлар өлеше, процент | 64,0 |
| Халыкның 100 мең кешесенә спорт корылмалары саны, берәмлек | 247 |
| Спорт объектларының бер тапкыр халык кабул итә алу мөмкинлеге, процент | 32,07 |
| Яшьләрнең гомуми санында сәләтле яшьләргә булышлык күрсәтү өлкәсендә башкарма хакимият органнары тормышка ашыра торган проектларга һәм программаларга җәлеп ителгән яшьләр өлеше арту, процент | 44,0 |
| Социаль әһәмияткә ия булган проектлар һәм программалар конкурсына тапшырылган гаризалар саны, берәмлек | 220 |
| Авыл яшьләренең гомуми санында социаль-икътисадый үсеш программаларында катнашучы авыл яшьләренең чагыштырма авырлыгы, процент | 49,2 |
| Балаларны һәм яшьләрне ялның оештырылган формаларына җәлеп итү, кеше | 213 |

**2. Авыл җирендә урнашкан Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру чаралары комплексын тормышка ашыруның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре**

а) Авыл җирендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының спорт залларын ремонтлау.

Бугенге көндә Татарстан Республикасында авыл җирендә урнашкан 857 гомуми белем бирү оешмасының спорт заллары бар. Шулардан авыл җирендә урнашкан 528 гомуми белем бирү оешмасында спорт залларына ремонт таләп ителә.

2012 елда Татарстан Республикасының гомуми белем бирү төбәк системасын модернизацияләү проекты (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 3 октябрь, б-1774 нче боерыгы) кысаларында 33 гомуми белем бирү оешмасында агымдагы ремонт үткәрелде. Моннан тыш, 3 гомуми белем бирү оешмасы спорт заллары (шул исәптән авыл җирендә урнашкан 1 гомуми белем бирү оешмасында) ремонтланды.

2013 елда капиталь ремонт программасы кысаларында (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 29 ноябрь, б-2129 нчы боерыгы) авыл җирендә урнашкан 81 гомуми белем бирү оешмаласында спорт заллары ремонланды. Җылыту системасын, тәрәзәләр алыштыру, түбә ябу эшләре башкарылды.

2014 елда авыл җирендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру программасы кысаларында авыл җирендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында 31 спорт залы ремонтланды.

2015 елда авыл җирендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының 38 спорт залында ремонт эшләре үткәрү планлаштырыла.

б) Булган аудиторияләрне физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен спорт заллары итеп үзгәртү.

Физик культура дәресләрен һәм дәрестән тыш спорт-савыктыру эшләрен үткәрү өчен Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары тарафыннан муниципаль дәрәҗәдәге спорт-савыктыру объектлары: спорт сарайлары, спорт комплекслары, боз сарайлары, йөзү бассейннары, стадионнар, ишегалды спорт мәйданчыклары актив файдаланыла.

2014 елда авыл җирендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру программасы кысаларында булган бер аудитория физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен спорт залы итеп үзгәртелде.

2015 елда күрсәтелгән эшләр күздә тотылмый.

в) Дәрестән тыш вакытта (гомуми белем бирүнең һәр дәрәҗәсе буенча) (мәктәпкәчә белем бирүдән тыш) физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче укучылар санын арттыру.

2015 елда – 1,6 процент, шул исәптән:

башлангыч – 1,3 процент;

төп – 1,9 процент;

урта – 1,6 процент.

г) Оешмаларда мәктәп спорт клубларын үстерү.

Татарстан Республикасында авыл җирендә урнашкан 93 белем бирү оешмасында мәктәп спорт клублары бар. 2015 елда өстәмә 30 клуб оештыру планлаштырыла.

д) Авыл җирендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының ачык яссы спорт корылмаларын спорт инвентаре һәм җиһазлары белән җиһазландыру.

2013 елдан Татарстан Республикасында авыл җирендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының ачык яссы спорт корылмаларын төзү һәм спорт җиһазлары белән җиһазландыру программасы тормышка ашырыла.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасы шәһәрләре һәм районнары микрорайоннарында һәм паркларында универсаль спорт мәйданчыкларын төзү максатларында акча бүлеп бирү турындагы 2013 ел, 4 декабрь, б-2486 нчы боерыгы нигезендә 2013 елда 59 ачык яссы спорт корылмасы төзелде.

2014 елда авыл җирендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру программасы кысаларында Татарстан Республикасы авыл җирлекләренең гомуми белем бирү оешмалары территориясендә 72 ачык яссы спорт мәйданчыгы төзелде.

2015 елда авыл җирендә урнашкан гомуми белем бирү оешмалары территориясендә 76 ачык яссы спорт мәйданчыгы төзү күздә тотыла. Әлеге корылмаларны спорт инвентаре һәм җиһазлары белән өстәмә җиһазландыру планлаштырылмый.

Авыл җирендә урнашкан Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру чаралары комплексын тормышка ашыруның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре, әлеге чараларны финанслау күләмнәре, шулай ук аларны тормышка ашыру буенча план-график тиешенчә бу Чаралар комплексына теркәлгән 1 – 3 нче кушымталарда китерелә.

___

2015 елда авыл җирендә урнашкан Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру чаралары комплексына 1 нче кушымта

## Авыл җирендә урнашкан Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру чаралары комплексын тормышка ашыруның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2014/2015 уку елы башына Россия Федерациясе субъектында укучыларның гомуми саны | | | 1 | 369 540 |
| 2014/2015 уку елы башына авыл җирендә урнашкан оешмаларда Россия Федерациясе субъектының укучылары саны | Барлыгы | | 2 | 82 454 |
| | гомуми саннан процент | | 3 | 22,3% |
| | Белем бирү дәрәҗәсе | Башлангыч | 4 | 30 658 |
| | | Төп | 5 | 42 694 |
| | | Урта | 6 | 8 115 |
| Авыл җирендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының гомуми саны | | | 7 | 955 |
| Спорт заллары булган авыл җирендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының гомуми саны | | | 8 | 857 |
| Ремонт таләп итеlә торган спорт заллары булган авыл җирендә урнашкан гомуми белем бирү оешмалары саны | Барлыгы | | 9 | 528 |
| | спорт заллары булган оешмаларның барлык санынннан процент | | 10 | 61% |
| Спорт заллары ремонтланган авыл җирендә урнашкан гомуми белем бирү оешмалары саны | Барлыгы | | 11 | 38 |
| | Тормышка ашыру вакыты | | 12 | 31.12.2015 г. |
| Физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен аудиторияләрне үзгәртүгә ихтыяҗлары булган авыл җирендә урнашкан гомуми белем бирү оешмалары саны | Барлыгы | | 13 | 0 |
| | оешмаларның барлык санынннан процент | | 14 | 0 |
| Физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен булган аудиторияләре спорт заллары итеп үзгәртеп ясалган авыл җирендә урнашкан гомуми белем бирү оешмалары саны | Барлыгы | | 15 | 0 |
| | Тормышка ашыру вакыты | | 16 | 0 |
| Дәрестән тыш вакытта гомуми белем | Белем бирү | Башлангыч | 17 | 37 704 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| бирүнең һәр дәрәҗәсе буенча (мәктәпкәчә белем бирүдән тыш) авыл җирендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче укучылар саны | дәрәҗәсе образования | Төп | 18 | 52 269 |
| | | Урта | 19 | 10 430 |
| | | Барлыгы | 20 | 100 403 |
| Дәрестән тыш вакытта (гомуми белем бирүнең һәр дәрәҗәсе буенча) физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче укучылар өлеше арту, мәктәпкәчә белем бирүдән тыш | Белем бирү дәрәҗәсе | Башлангыч | 21 | 1,3% |
| | | Төп | 22 | 1,9% |
| | | Урта | 23 | 1,6% |
| | | Барлыгы | 24 | 1,6% |
| | | Тормышка ашыру вакыты | 25 | 31.12.2015 г. |
| Мәктәп спорт клублары булган авыл җирендә урнашкан гомуми белем бирү оешмалары саны | Барлыгы | | 26 | 93 |
| | оешмаларның барлык саныннан процент | | 27 | 9,7% |
| Физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен авыл җирендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында оештырылган мәктәп спорт клублары саны арту | Барлыгы | | 28 | 30 |
| | Тормышка ашыру вакыты | | 29 | 31.12.2015 г. |
| Ачык яссы спорт корылмаларын спорт инвентаре һәм җиһазлары белән җиһазландыруга ихтыяҗлары булган авыл җирендә урнашкан гомуми белем бирү оешмалары саны | Барлыгы | | 30 | 0 |
| | оешмаларның барлык саныннан процент | | 31 | 0 |
| Ачык яссы спорт корылмалары спорт инвентаре һәм җиһазлары белән җиһазландырылган авыл җирендә урнашкан гомуми белем бирү оешмалары саны | Барлыгы | | 32 | 0 |
| | Тормышка ашыру вакыты | | 33 | - |

___

2015 елда авыл җирендә урнашкан Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру чаралары комплексына 2 нче кушымта

2015 елда авыл җирендә урнашкан Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру чаралары комплексын финанслау күләмнәре

<table>
<tr><td rowspan="4">Т/с</td><td rowspan="4">Чаралар исеме</td><td colspan="6">Финанслау күләмнәре, мең сум</td></tr>
<tr><td rowspan="3">барлыгы</td><td colspan="5">шул исәптән</td></tr>
<tr><td rowspan="2">федераль бюджет</td><td colspan="4">Татарстан Республикасы бюджеты</td></tr>
<tr><td>барлы-гы</td><td>төбәк бюджеты</td><td>җирле бюджет-лар</td><td>бюджет-тан тыш чыга-наклар</td></tr>
<tr><td>1.</td><td>Спорт залларын ремонтлау</td><td>57 000</td><td>42 000</td><td>15 000</td><td>15 000*</td><td>0</td><td>0</td></tr>
<tr><td></td><td>БАРЛЫГЫ</td><td>57 000</td><td>42 000</td><td>15 000</td><td>15 000*</td><td>0</td><td>0</td></tr>
<tr><td colspan="8">* Акча 2010 – 2015 елларга Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү буенча «Киләчәк» – «Будущее» стратегиясен тормышка ашыруга «2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законында күздә тотылды.</td></tr>
</table>

F:\KARAR\2015\100-1.doc

2015 елда авыл җирендә урнашкан Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру чаралары комплексына 3 нче кушымта

2015 елда авыл җирендә урнашкан Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру чаралары комплексын тормышка ашыру буенча план-график

| Т/с | Чаралар исеме | Чараларны тормышка ашыру вакыты | | | | Чараларны тормышка ашыру өчен җаваплы Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы исеме |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2015 елның I квар-талы | 2015 елның II квар-талы | 2015 елның III квар-талы | 2015 елның IV квар-талы | |
| 1. | Спорт залларын ремонтлау | х* | х | х | х | Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |
| * «Х» билгесе белән хисап кварталында үткәрелә торган чаралар билгеләнде. | | | | | | |

F:\KARAR\2015\100-1.doc